ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.01.2024 п.г.т. Алексеевское № 13

**Алексеевск муниципаль районында «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсын үткәрү буенча муниципаль конкурс комиссиясен төзү турында**

«Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында «2015 елның 1 июнендәге 391 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында Нигезләмәгә туры китереп һәм «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе президиумының 30.12.2023 ел, №ПР-105-1 карары нигезендә,

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районында «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» Республика конкурсын үткәрү буенча муниципаль конкурс комиссиясен төзергә һәм аның эш регламентын расларга (1,2 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ /alekseevskiy.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
15.01.2024 ел, № 13 карарына
1 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районында «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» Республика конкурсын үткәрү буенча муниципаль конкурс комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

**Комиссия рәисе:**
Гайсин М.Р. – Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

**Комиссия рәисе урынбасары:**
Свистунов И.К. – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча)

**Комиссия секретаре:**
Увакина В.В. – Алексеевск шәһәр җирлеге Советы Рәисе урынбасары (килештерү буенча)

**Комиссия әгъзалары:**
Тимонина Н.Ю. – «Алексеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ җитәкчесе
Йосыпова Г.Ә. – Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
15.01.2024 ел, № 13 карарына
2 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районында «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын үткәрү буенча муниципаль конкурс комиссиясе эшенең Регламенты**

1. Алексеевск муниципаль районында «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсының муниципаль конкурс комиссиясе утырышы (алга таба - Комиссия) хокуклы, әгәр анда аның исемлек составының өчтән ике өлеше катнашса.

2. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм Комиссия әгъзаларының 50 проценттан артыгы тавыш биргән очракта кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта Комиссия рәисе тавышы хәл иткүче булып тора.

3. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә һәм комиссия рәисе һәм әгъзалары тарафыннан Комиссия утырышы уздырылган көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә имзалана.

4. Комиссия эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә, гаризаларны кабул итү вакыты башланган көннән башлап, конкурсның I этабында катнашу өчен гаризаларны кабул итә һәм терки.

5. Комиссия эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә, гаризалар кабул итү тәмамланган көннән башлап, «Татарстан Республикасы елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иң яхшы территориаль конкурс турында» 2015 елның 1 июнендәге 391 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» Республика конкурсы турында нигезләмәгә 4 нче кушымта нигезендә, конкурсның I этабында катнашуга тәкъдим ителгән гаризаларны бәяләүне гамәлгә ашыра һәм конкурсның II этабында катнашырга дәгъва итүчеләрне билгеләнгән тәртиптә билгели.

6. Конкурсның I этабын үткәрү нәтиҗәләре буенча Комиссия конкурсның II этабына тәкъдим итә:

1) Нигезләмәгә 2.1 нче кушымта нигезендә форма буенча «Татарстан Республикасының Елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсының II этабында катнашу турында гариза;

2) комиссия төзелгән һәм аның составы расланган муниципаль хокукый актның күчермәсе;

3) Конкурсның I этабында катнашучыларның исемлеге;

4) муниципаль конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан имзаланган муниципаль конкурс комиссиясе утырышының йомгаклау беркетмәсе;

5) Нигезләмәнең 3.9 пунктына ярашлы рәвештә конкурсның II этабында катнашуга дәгъва кылучы катнашучыларның гаризалары.

7. Комиссия карарлары катнашучылар һәм дәгъвачылар тарафыннан билгеләнгән закон тәртибендә шикаять ителергә мөмкин.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**